РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
**Исполнительный комитет**
**Большебуртасского сельского**
**поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

422833, с.Большие Буртасы, ул Ленинградская 27
тел. (884377) 33-6-42 факс: (884377) 33-6-42
ОГРН 1061672020080 ИНН/КПП
1622004683/162201001

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Олы Бортас авыл жирлеге**
**Башкарма комитеты**

422833, Олы Бортас авылы, Ленинград ур 27
тел. (884377) 33-6-42 факс: (884377) 33-6-42
ОГРН1061672020080 инн/кпп 1622004683/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 29 гыйнвары №1

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлегендә 2021 елга җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авылы җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авылы җирлегендә җирләү буенча хезмәт күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләргә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә 6424 сум 98 тиен күләмендә бәя куярга һәм 2021 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлегенең «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән

исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында»  2020 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Бортас авылы, Ленинград ур., 27;
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Балчыклы авылы, Ленин урамы, 70 нче йорт,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга .

4. Әлеге карар 2021 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Олы Бортас
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе:                                   Р. С. Сәгдиев

Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлегендә җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең бәяләре

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3850,02 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 547,86 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2027,10 |
| Барлыгы | 6424,98 |

Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Бортас авыл җирлеге башкарма
комитетының 2021 елның 29
гыйнварындагы 1 номерлы карарына
2 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләрнең
бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 197,58 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3652,44 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка озату | 547,86 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2027,10 |
| Барлыгы | 6424,98 |